A. T. S. S. Ç. Qazan LENIN isem.
ÖLKƏ MASSA KITAPXANƏSE TӨP KITAP SAQLAY BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ ТАССР г. Казань

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ЧӘРШӘМБЕ
6 МАРТ
1940 ел
№ 54 (5854)
Аерым номеры 10 тиен

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

КОМСОМОЛ һӘМ ПРОПАГАНДА

Бөек партиябез тарихи XVIII нче съездда кабул ителгән устав нигезендә комсомолның ролен яңа югарылыкка күтәрде, комсомол оешмалары алдына яшьләрне коммунистик рухта тәрбияләү белән бергә, дәүләт һәм хуҗалык эшендә актив катнашу кебек гаять мөһим бурычлар куйды.

Партиянең XVIII нче съезды тарафыннан куелган бу зур һәм җаваплы бурычларны комсомолецлар бары тик үзләренең идея-политик белем дәрәҗәләрен өзлексез күтәрә барганда гына, марксизм-ленинизм теориясе белән чын-чыннан коралланганда гына тулысынча үти алалар.

Комсомол үз сафларында социалистик дәүләтнең булачак җитәкче кадрларын тәрбияли. Социалистик дәүләтне идарә итү өчен, аның политик-хуҗалык, культура тормышына дөрес юнәлеш бирә белү өчен барыннан да элек, җәмгыятьнең үсеш һәм политик көрәш законнарын белергә, Маркснын—Ленинның революцион теориясен үзләштерергә кирәк. Иптәш Жданов ВЛКСМ Үзәк Комитетының комсомолның XX еллыгына багышланган тантаналы пленумында сөйләгән речендә: „Сез социалистик дәүләтебезнең киләчәктәге җитәкчеләре, ә сезнең бер өлешегез хәзер үк инде дәүләт эшенең төрле тармакларының җитәкчеләре. Дәүләт, хуҗалык, кооперация һәм башка эшләрдә төрле постларда эшләүче җитәкче комсомол кадрларының саны көннән-көн үсәр. Бу, комсомолны, беренче чиратта аның кадрларын марксизм-ленинизм теориясен ныклап үзләштерүгә тотынырга мәҗбүр итә“.

Ленин—Сталин комсомолы дәүләт һәм хуҗалык төзелешендә үзенең роле нинди булырга тиешлек турында партиябез тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрне бөтен тирәнлеге белән үзләштерде һәм ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң үткән чор эчендә үзенең эшен яңа баштан үзгәртеп коруда шактый уңышларга иреште. Моны ВЛКСМ ның Татарстан өлкә оешмасы мисалендә дә ачык күрергә мөмкин.

Мәсәлән, ВЛКСМ ның Әлмәт райкомы комсомолның өлкә оешмасының IV нче пленумыннан соң гына да, күп кенә комсомолецларны һәм союздан тыш яшьләрне политукуларга тартты, яңадан дүрт урында политграмота түгәрәкләре оештырып, аларга хәзерлекле җитәкчеләр беркетте. Хәзер бу районда 204 комсомолец үзлекләреннән һәм 48 комсомолец түгәрәкләрдә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнәләр. Комсомол активы марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүдә тырышып эшли һәм рядовой комсомолецларга бу эштә үрнәк күрсәтә. ВЛКСМ райкомы секретаре Әхметшина, райкомолның пропаганда бүлеге мөдире Ситдиков, райком пленумы члены Галимов һәм башка күп кенә иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н бер кат өйрәнеп конспект төзеделәр инде. Бу иптәшләр хәзер Маркс, Энгельс, Ленин, Сталинның аерым әсәрләрен өйрәнәләр.

ВЛКСМ ның Лаеш райкомы да Өлкә Комитеты пленумыннан соң пропаганда эшен шактый көчәйтте, райком җитәкчеләре пропагандага җитәкчелек итү эшен үз кулларына алдылар. ВЛКСМ райкомы пленумы члены иптәш Ивановский „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н конспект төзеп укып чыкты. Хәзер ул Ленинның, Сталинның аерым әсәрләрен өйрәнә. Иптәш Ивановский үзенең теоретик хәзерлеген өзлексез күтәрүе нәтиҗәсендә счетоводлык эшеннән райфо мөдире булып күтәрелде.

ВЛКСМ ның Әгерҗе, Столбище райкомнарының җитәкче работниклары да үзләренең теоретик хәзерлекләрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр.

Ләкин барлык районнарда да комсомол пропагандасы яхшы тора дип булмый әле. „Марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүдә үзләре үрнәк күрсәтү урнында комсомолның күп кенә җитәкче работниклары ВКП(б) тарихын өйрәнү кирәклек турында яңгыравыклы речьләр сөйләүне артыграк күрәләр, ә үзләре—теоретик яктан артта калалар“ (ВЛКСМ Үзәк Комитеты карарыннан).

Мәсәлән, ВЛКСМ ның Тельман райкомы секретаре иптәш Шмилев марксизм-ленинизмны өйрәнү белән үзе дә шөгылләнми, пропаганда эшенә дә җитәкчелек итми. Бу районда комсомол пропагандасы үз агымына куелган, кемнең ничек өйрәнгәнен, кемгә нинди ярдәм кирәклеген райкомда берәү дә белми.

ВЛКСМ ның Чүпрәле райкомы секретаре иптәш Галиев, ВЛКСМ ның Балык Бистәсе райкомы секретаре Чукуров, Аксубай райкомы секретаре Борисов һәм Кызыл Армия, Красный Бор, Питрәч райкомнары секретарьлары да марксизм-ленинизмның революцион теориясен өйрәнү өстендә эшләмиләр. Бу районнарда комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында политик-тәрбия эшләренең торышы начар.

Комсомол оешмаларының төп бурычлары — пропаганда эшендәге кимчелекләрне һәм пропаганда эшен үз агымына куюны бетерүдән, комсомол активының марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүенә контроль булдырудан гыйбарәт.

ВЛКСМ райком бюросы утырышларында, комсомолецларның гомуми җыелышларында, ВЛКСМ членнары арасында политукуларның торышын әледән-әле тикшереп торырга, үз өстендә эшләмәгән комсомол членнарына карата җәмагат фикрен тупларга кирәк.

Беседалар үткәрү, популяр докладлар, лекцияләр һәм парткабинетлар янында консультация оештыру юлы белән ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә иптәшләрчә көндәлек булышлык оештырырга кирәк.

Партия оешмалары революцион теорияне өйрәнү эшендә комсомолга көндәлек булышлык күрсәтергә, комсомол оешмаларын теоретик хәзерлекләре җитәрлек булган пропагандистлар белән тәэмин итәргә тиешләр. Татарстан комсомолы ВКП(б) һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетларының пропаганда эшенең куелышы турындагы карарлары нигезендә үзенең эшен үзгәртеп корырга һәм пропаганда эшендәге кимчелекләрне бетерергә тиеш.

Партиянең Казан Шәһәр Конференциясе

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты IV нче конференция карарларын үтәү буенча, партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын үтәүне оештыру буенча күп кенә эшләр башкарган. Промышленность предприятиеләренең күпчелегендә предприятие администрациясенең эшенә контроль ясауны дөрес оештыру һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча күп кенә оештыру чаралары үткәрү, партия-политик эшне көчәйтү нәтиҗәсендә, производство планнары арттырылып үтәлгән. Кадрлар сайлап алу һәм аларны тәрбияләү, ВКП(б) сафларын үстерү, партияле һәм партиясез большевиклар арасында марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнүне оештыру буенча да шактый эшләр эшләнгән. Конференциядә чыгып сөйләүче делегатлар партиянең шәһәр оешмасы ирешкән бу уңышларны конкрет саннар һәм фактлар белән күрсәтеп үттеләр. Шуның белән бергә, ВКП(б) Шәһәр Комитетының практик эшендә зур гына җитешсезлекләр булуы да күрсәтелде. Доклад буенча фикер алышуларда катнашучы иптәшләрнең күпчелеге партия пропагандасының куелышына, хезмәт ияләре арасында коммунистик тәрбия эшләренең торышына тукталдылар.

—Марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнүне оештыру буенча ВКП(б) Шәһәр Комитеты зур гына эшләр үткәрде,—ди партиянең Сталин райкомы секретаре иптәш Гаязеттинов,—ләкин бу әле эшнең башлангычы гына, большевизмны үзләштерүне оештыру һәм бу өлкәдә җидди уңышларга ирешү өчен күп эшлисе бар һәм ул уңышларны яулап алырга кирәк. Моның өчен, иң беренче чиратта, партия активы, җитәкче работниклар үзләре марксизм-ленинизм фәнен өйрәнү өлкәсендә үрнәк күрсәтергә тиешләр. Ә чынында бу эш ничек тора соң? Дөресен әйтергә кирәк: бик үк мактарлык тормый.

Татарстан Эчке Эшләр Халык Комиссариаты работнигы иптәш Матвеев ВКП(б) Өлкә Комитетының VII нче һәм VIII нче пленумы карарларының ничек үтәлүенә туктала. Ул болай ди:

— Партиянең Шәһәр Комитеты ВКП(б) Өлкә Комитетының VII нче һәм VIII нче пленумы карарларын кирәгенчә үтәмәде. Бу карарлар партия сафларын регулярләштерүне, кандидатлар арасында эшләүне кискен рәвештә көчәйтүне таләп иткән иде. Ә фактта без моның киресен күрәбез. ВКП(б) ның шәһәр оешмалары тарафыннан партия сафына кабул ителгән кешеләр арасында эшчеләрнең аз булуы һәм кандидатлар арасында 991 иптәшнең кандидатлык стажлары үткән булу моны тулысынча раслый. Болар барсы да ВКП(б) сафларын үстерү эше белән системалы рәвештә шөгыльләнмәү нәтиҗәсендә килеп чыкканнар. ВКП(б) Шәһәр Комитетының яңа составы бу җитешсезлекләрне искә алырга һәм аны киләчәктә кабатламаска тиеш.

ВКП(б) ның Киров райкомы секретаре иптәш Тихонов промышленность предприятиеләренә һәм стахановчылык хәрәкәтенә партия оешмаларының җитәкчелегенә, бу өлкәдә булган кимчелекләргә туктала.

— Промышленность предприятиеләренең бер өлеше 1939 нчы ел планын үтәмәде, мин бирелә Җитен комбинаты шикелле предприятиеләрне күздә тотам, бу комбинатта эшләүче коммунистларның бары 7 проценты гына стахановчылар, моны без отчетка хәзерләнә башлагач кына белдек—ди иптәш Тихонов. Аннары, ул үзенең речендә трамвай хуҗалыгының начар эшләвен каты тәнкыйть уты астына ала һәм бу өлкәдә кискен борылыш ясау кирәклеген күрсәтә.

Казан Химия-Технология институты директоры иптәш Суриков, югары уку йортларына җитәкчелек һәм студентлар арасында политик-тәрбия эшләренең торышына тукталып, болай ди:

— Казан ВУЗлар шәһәре, бу нәрсә ВКП(б) Шәһәр Комитеты өчен билгеле. Ләкин без югары уку йортларына Шәһәр Комитетының җитәкчелеге канәгатьләнерлек тора дип әйтә алмыйбыз. Студентлар арасында дисциплинаның йомшак булуын аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Быелгы сессияләр вактында Казан ВУЗларындагы студентларның 9 проценты аттестацияләр аркылы үтмәү—студентлар арасында дисциплинаның түбән булуын күрсәтә.

— Комсомол һәм пионер оешмалары үзләренең эшләрен яхшы куйган урыннарда уку-укыту эшләре дә яхшы бара,—ди ВЛКСМ ның ШәһәрКомитеты секретаре иптәш Иванов үзенең чыгышында.—Моның шулай булуын 39 нчы мәктәпнең практикасы ачык күрсәтә. Бу мәктәптә укучылар 100 процент өлгереш бирәләр. Ә менә Сталин районындагы 78 нче мәктәп кебек эшне үз агымына куйган урыннарда моның киресенчә, укучыларның өлгерүләре 67—70 процентлан да артмый. Шулай булгач, мәктәпләрдә комсомол һәм пионер эшләрен көчәйтергә кирәклеге үзеннән-үзе билгеле. Без, комсомол работниклары, бу мәсьәләгә җидди әһәмият бирергә тиешбез.

ВКП(б) Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Нацибуллин үзенең чыгышында кадрлар сайлап алу һәм аларны тәрбияләү мәсьәләләренә туктала, отчет чоры эчендә ВКП(б) Шәһәр Комитеты бу өлкәдә шактый эш башкарган. Партияле работниклардан 850 иптәш җитәкче эшләргә күтәрелгән.

— Ләкин бу эшләр генә безне һич тә канәгатьләндермиләр, кадрларны өйрәнү, тәрбияләү өлкәсендә зур кимчелекләр бар һәм аларны бик тизлек белән бетерергә кирәк,—ди иптәш Нацибуллин.

Партиянең Казан шәһәр оешмасының V нче конференциясендә Бауман районы делегатларыннан бер төркем. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): Ш. Вәлиев, З. Шаһиәхметов, М. Е. Попова, Н. Е. Войтович һәм П. М. Берг иптәшләр.
И. Галиев фотосы.

Аннан соң Барышников (Мехкомбинат), Труфанов (Киров районы), Михайлов (Ленин районы), Рыков (ВКП(б) Шәһәр Комитеты), Христофоров (Осоавиахим Үзәк Советы) иптәшләр чыгып сөйләделәр.

⁂

5 нче мартта, иртәнге утырышта отчет доклады буенча фикер алышулар дәвам итте. **Арнаутов** (Казан Финанс-Экономика институты), **Румянцев** (Казан Авиация институты) иптәшләр югары уку йортларында марксизм-ленинизм нигезләре фәнен укыту эшләренең тиешле югарылыкта тормавы һәм ул фәннәрне укыту эшен яхшырту мәсьәләсе белән Шәһәр Комитетының йомшак шөгыльләнүе турында сөйләделәр.

Иптәш **Измайлова** (Опера театры) театрлар һәм башка сәнгать учреждениеләре җитәкчелеген хәзерлекле кадрлар белән ныгыту мәсьәләсендә Шәһәр Комитетының тиешенчә эшләмәвен каты тәнкыйть итте.

Совет Контроле Комиссиясенең Татарстан буенча уполномоченные иптәш Рундаев үзенең чыгышында совет аппаратының эш стиле һәм шәһәр тирәсе хуҗалыгының торышы турындагы мәсьәләләргә тукталды. Аерым учреждениеләр эшендәге культурасызлык һәм бюрократизм күренешләрен тәнкыйть уты астына алды.

Партиянең Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Мөхәмәтов** партия пропагандасы һәм җитәкче работниклар арасында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү эшенең торышы турында речь белән чыкты. Ул, „кыскача-курс“ны өйрәнү эше белән аерым җитәкче работникларның начар шөгыльләнүләрен күрсәткән күп кенә конкрет фактлар китерде. Киләчәктә партия пропагандасын яхшыртуның практик чаралары турында сөйләде.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Бычков райкомнарда да, Шәһәр Комитетында да билгеләнгән чараларның, чыгарылган карарларның үтәлешенә контроль ясау эшенең торышы канәгатьләнерлек булмавы турында күрсәтеп үтте.

Иртәнге утырышта фикер алышуларга шулай ук **Кузьмин** (Мехкомбинат), **Шпаков**, **Чиликин** (Энергокомбинат), **Ерин** (Казан тимер юлы узелы), **Абдрашитов** (ВКП(б) ның Бауман райкомы), **Орехов** (Шәһәр советы башкарма комитеты), **Бурнашев** (Н часте), Вәлиев (җиркомбинат) иптәшләр дә катнаштылар һәм шуның белән фикер алышулар тәмам булды.

Отчет доклады буенча фикер алышуларда барлыгы 41 кеше чыгып сөйләде.

Конференциянең 5 нче марттагы кичке утырышында иптәш Алемасовның йомгаклау сүзе булды. Аннан соң мандат комиссиясе председателе иптәш Хәмидуллинның доклады тыңланды.

Конференция ВКП(б) Шәһәр Комитетының политик линиясен дөрес дип, практик эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Бүген Шәһәр Комитеты составына сайлаулар була.

СССР БЕЛӘН ГЕРМАНИЯНЕҢ КАТНАШ ҮЗӘК ЧИК БУЕ КОМИССИЯСЕНЕҢ БЕЛДЕРҮЕ

1940 нчы елның 27 нче февралендә Совет—Германия арасындагы 1.500 километр чамасы чикнең бөтен буена чик билгеләре кую тәмам булды. Барлыгы 2.820 чик баганасы куелды.

Яңа чикне топографиягә алу нигездә тәмам булды.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

4 нче мартта Карелия бугазында Выборг заливы районында безнең частьләр **Ууран-Саари** атавын һәм андагы **Тронгсунд (Уураа)** шәһәрен һәм крепостен, Выборг заливында **Тейкарин-Саари** атавын, шулай ук Выборг заливының көнбатыш ярында **Хейнлахти, Вилаиоки** һәм **Мухулахти** местечколарын алдылар. **Тронгсунд** крепостенда еракка ата торган диңгез орудиеләреннән торган өч батарея һәм күп санда пулеметлар, винтовкалар, снарядлар һәм патроннар кулга төшерелде.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына сугыш хәрәкәтләре алып барды. Һавада дошман авиациясе күренмәде.

ВКП(б) ның Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе делегатлары игтибарына

Партиянең Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе шушы елның 10 нчы мартында, 18 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта ачыла. (Казан, Карл Маркс урамы, 26).

Делегатларны теркәү һәм делегатлык билетлары бирү 8 һәм 9 нчы мартта 9 сәгатьтән 23 сәгатькә кадәр һәм 10 нчы мартта 9 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бинасында, 35 нче бүлмәдә булачак (Казан, Б. Красный урам, 38). Оештыру комиссиясенең телефоннары: 26—80, 13—30, яки Өлкә Комитеты коммутаторы аркылы—10.

Оештыру комиссиясе.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Чәчүлек орлык белән колхозара ярдәмләшү

Мамадыш районының „Хәсәнша“ колхозы членнарының тулай җыелышы булды. Анда „КИМ“ колхозына орлык һәм фураж белән үзара ярдәм итү турындагы мәсьәлә тикшерелде. Беренче булып чыгыш ясаган колхозчы иптәш Хәсәнов болай диде:

— Безнең колхоз бар яктан да районда алдынгылардан исәпләнә. Без „КИМ“ колхозына орлык һәм фураж белән ярдәм итеп, бу мәсьәләдә үрнәк күрсәтергә тиешбез. Бездә моңа мөмкинлек бар. Колхозчылар үзләре дә 100 центнерга якын орлыкны бурычка бирә алалар.

Җыелыш иптәш Хәсәновның тәкъдимен кайнар рәвештә яклап, „КИМ“ колхозына 335 центнер орлык һәм 195 центнер фураж бирергә карар бирде. Җыелыштан соң ук „КИМ“ колхозына җыелышның бу карары турында хәбәр җибәрелде.

„КИМ“ колхозына „Игенче“ колхозы членнары да 164 центнер орлык белән ярдәм итәргә карар бирделәр.

⁂

Норлат районы колхозларында чәчүлек орлык белән үзара социалистик ярдәм күрсәтү киң җәелә. Чәчүлек орлыклары җитәрлек булмаган колхозларга „Совет“ колхозы—250 центнер, „Көчле Ирек“ колхозы—280, „Волховстрой“ колхозы—200 центнер, „Красный Дол“ колхозы—80, „Свобода“ колхозы—80, „Кызыл Байрак“ колхозы—70 центнер орлык бирделәр.

„Победа“, „Труд“, „Молот“, Куйбышев исемендәге һәм Калинин исемендәге колхозлар үзара социалистик ярдәм тәртибендә 1.380 центнер орлык алдылар.

⁂

Кукмара районының алдынгы колхозлары чәчүлек орлык белән үзара социалистик ярдәм күрсәтәләр. „Победа“ колхозы социалистик ярдәм тәртибендә „Труженик“ колхозына 137 центнер, „Тигезлек“ колхозы „Туры юл“ колхозына 200 центнер чәчүлек орлык бурычка бирде.

Ләкин районда чәчүлек орлык белән үзара ярдәм оештыруның политик һәм хуҗалык әһәмиятен аңларга теләмәгән „җитәкчеләр“ дә бар әле. Мәсәлән, „Кустарь“ колхозының председателе иптәш Мәннапов башка колхозларга ярдәм итүдән баш тарта. Ә колхозда 147 центнер чәчүлек орлык артып кала.

(ТатТАСС).

Һәрбер нәрсәне алдан хәзерләп куярга

АКТАНЫШ, 5 март. (**Телефон буенча**). Без тракторларга һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясауны күптән тәгәлләдек. Ремонтның сыйфаты яхшы. Бригада өчен кирәкле инструментлардан мичкә, чиләк кебек әйберләрнең барсын да хәзерләп куйдык. Тракторчылар үзләренең кайсы колхозда һәм кайсы бригадада эшләячәкләрен беләләр.

Ләкин әле бу, бригадада язгы чәчүгә хәзерлек бөтенләй тәгәлләнде дигән сүз түгел.

Без барлык машиналарны 15—20 нче марттан да соңга калмыйча колхозларга күчерәбез. Бу вакытта әле кыр эшләренә керешергә кимендә 10—15 көн, кайбер елларны аннан да артык вакыт була. Менә шушы чорда бригадада эшләячәк кешеләрне—прицепщикларны, орлык ташучыларны, аш пешерүчеләрне, су китерүчеләрне билгеләү эшләрен башкарабыз. Бу чара югарыда күрсәтелгән кешеләрнең машина янында үзенә тапшырылган эшкә көче җитү, булдыра алу принципыннан чыгып эшләнә. Шулай ук колхозларның үзләрендәге эш көчләрен дөрес урнаштыруга нык игтибар бирәбез. Бер бригададан аш пешерүче алынса, икенче бригададан башка кешеләр алына. Бу кешеләр кыр эшләре беткәнгә кадәр бригадага беркетеләләр.

Бригадага ярдәмче көчләр туплангач аларны бригаданың эчке тәртип кагыйдәләре белән һәм үзләренә беркетелгән машиналарны идарә итү техникасы белән таныштырабыз.

Бригадада социалистик ярыш договорлары төзелә. 3 республика ярышының конкрет йөкләмәләре белән танышалар, өйрәнәләр. Шул ук вакытта культуралы вагоннар җиһазландырыла, көтепханә, газета-журнал һәм башка әйберләр булдырыла. Без барлык „вак-төякләрне“ дә күздә тотабыз. Савыт-саба, утын кебек кирәкле нәрсәләр хәзерлибез. Басуларга чыкканчы бөтен нәрсә хәзер булырга тиеш. Без бу эшләрне колхоз правлениеләре белән бергә эшлибез.

Трактор бригадасының яхшы эшләве һәм колхозда кырчылык бригадасының югары иген уңышы алуга ирешүе бу ике бригаданың бергәләп эшләвенә нык бәйләнгән. Шуның өчен дә без трактор бригадасы белән кырчылык бригадасы арасында договор төзибез. Кырчылык бригадасы үз бригадасында барлык агротехника чараларын тулысынча тормышка ашырып, үзенең эшен трактор бригадасының эшенә тоткарлык ясамаслык итеп үтәргә йөкләмә ала. Трактор бригадасы исә үз эшен отлично һәм яхшы билгеләренә тапшыру һәм һәр эшне вактында үтәү йөкләмәсен ала. Шулай итеп машиналарның яхшы эшләүләре һәм югары иген уңышы алуга ирешү өчен без бергәләп көрәшәбез.

Гобәйдулла Ганиев.
Актаныш МТС ның Алтын медаль белән бүләкләнгән бригадиры.

Партиянең район конференцияләре һәм җыелышлары

Партиянең Шөгер район конференциясе

Партиянең Шөгер район конференциясендә отчет доклады буенча фикер алышуларда 28 кеше катнашты. Чыгып сөйләүче иптәшләр ВКП(б) райкомының эшендәге уңышларны күрсәтү белән бергә, аның җидди кимчелекләрен көчле тәнкыйт уты астына алдылар.

Отчет чорында райком шактый уңышларга ирешкән. 1939 нчы елны гына да ВКП(б) члены итеп 83, кандидат итеп 79 кеше кабул ителгән. Отчет чорында 12 урында башлангыч партоешмалар оештырылган. Шул вакыт эчендә районның алдынгы яшьләреннән 600 кеше комсомолга кергән. Алдынгы комсомолецлардан 100 кеше партиягә кабул ителгән.

Делегатлар колхоз партоешмаларына райком секретарьларының оператив җитәкчелек итмәүләрен, райком аппаратында бюрократлык фактларының булуын күрсәттеләр. Райком җитәкчеләре Акчурин, Чернышов һәм Әхмәтҗанов иптәшләр соңгы дүрт ай эчендә бер колхозда да булмаганнар.

Коммунистларны марксизм-ленинизм рухында тәрбияләү эше начар куелган. Районда 87 коммунист „кыскача курс“ны өйрәнү эшенә керешмәгән дә. Район газетасы да бу мөһим эшкә тиешенчә игътибар итмәгән.

Фикер алышуларда катнашучы коммунистлар партиянең район оешмасы эшен тагын да яхшырту өчен күп кенә практик тәкъдимнәр керттеләр.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына 21 кеше сайланды.

Райкомның беренче пленумы булып үтте. Пленум, райкомның беренче секретаре итеп Иматетдинов һәм икенче секретаре итеп Чернышов иптәшләрне сайлады.

В. Хәлимов.

Зур активлык

(Үз хәбәрчебездән телефон буенча)

Әлмәт районы большевикларының беренче район конференциясе үзенең эшен тәмамлады. Конференция зур активлык белән үтте. Фикер алышуларда 41 делегат чыгып сөйләде. Алар уңышлы якларны күрсәтү белән бергә, райкомның эшендә булган җидди кимчелекләрне кыю рәвештә тәнкыйтьләделәр.

Конференция отчет - доклады буенча карар кабул итте, ВКП(б) райкомының политик линиясен дөрес һәм практик эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

27 кешедән райком пленумы составы сайланды. 1 нче мартта райком пленумының беренче утырышы булып үтте. Пленум ВКП(б) райкомының беренче секретаре итеп Бикбов, икенче секретаре итеп Фазлиев, өченче секретаре итеп Саттаров иптәшләрне сайлады, шулай ук 7 кешедән бюро составы сайлады.

З. Салахеттинов.

Конференция оешкан рәвештә үтте

Партиянең Саба район конференциясендә тавыш бирү хокукы белән 72 һәм киңәш бирү хокукы белән 12 делегат катнашты.

Конференциядә коммунистлар зур активлык күрсәттеләр. Райкомның эше турында отчет-доклады буенча фикер алышуларда 36 кеше чыгыш ясады.

Конференция райкомның политик линиясен дөрес һәм эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Партиянең район оешмасы җитәкчелегенә сайлаулар шулай ук оешкан рәвештә үтте.

Г. Галиева.

Арча районында

Арча районының партконференциясе булып үтте. Райком отчеты буенча фикер алышуларда делегатлардан 42 кеше катнашты. Конференция райкомның эшен канәгатьләнмәслек дип тапты һәм эшне яхшырту буенча практик чаралар билгеләде.

Конференция 23 кеше составында пленум сайлады. Алар арасында 2 хатын-кыз һәм 11 кеше райкомга беренче тапкыр сайланучылар. XXI нче өлкә партконференциягә тавыш бирү хокукы белән 4 һәм киңәш бирү хокукы белән 2 делегат сайланды.

Райком пленумы райкомның беренче секретаре итеп Бәдретдинов, икенче секретаре итеп Мөхәмәтҗанов, кадрлар буенча секретарь итеп Дышаев иптәшләрне сайлады. Оештыру - инструкторлык бүлегенә Зәйнуллин, пропаганда - агитация бүлегенә Хөсәенов, хәрби бүлеккә Волков иптәшләр бүлек мөдирләре итеп, Рамазанов һәм Кирилловский иптәшләр район газеталарының редакторлары итеп расландылар.

Н. Мәҗитов.

САЙЛАУЛАР ХРОНИКАСЫ

Зеленодольски шәһәренең беренче конференциясе тәмам булды. Аңа тавыш бирү хокукы белән 105, киңәш бирү хокукы белән 36 делегат катнашты.

Шәһәр комитетының беренче пленумы 7 кеше составында бюро сайлады. Беренче секретарь итеп Суганов, икенче секретарь итеп Нигмәтҗанов, кадрлар буенча секретарь итеп Васильева иптәшләр сайланды.

☘

Партиянең **Кукмара** район конференциясендә ВКП(б) райкомының отчет доклады буенча фикер алышуларда „30 кеше чыгыш ясады.

Конференция ВКП(б) райкомының эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә райком пленумының, ревизия комиссиясенең яңа составына членнар һәм партиянең өлкә конференциясенә делегатлар сайланды.

Конференциядән соң райком пленумы булып, анда райком секретарьлары сайланды һәм бүлек мөдирләре расланды. Райком секретарьлары итеп Шульдеев, Закиров һәм Сизаев иптәшләр сайланды.

☘

Партиянең **Лаеш** район конференциясе райкомның эшен канәгатьләнмәслек дип тапты. Ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына 21 член һәм 5 кандидат, ревизия комиссиясенә 5 член сайланды. Партиянең өлкә конференциясенә делегат итеп тавыш бирү хокукы белән Огольцов һәм Камашева иптәшләр, киңәш бирү хокукы белән иптәш Гайнуллин сайланды.

2 нче мартта райкомның беренче пленумы булды. 7 членнан бюро төзелде. Райкомның беренче секретаре итеп Огольцов, икенче секретаре итеп Магсумов, кадрлар буенча секретарь итеп Карпов иптәшләр сайланды.

☘

Яңа Писмән районы коммунистларының отчет-сайлау җыелышы булды. Фикер алышуларда 37 кеше катнашты. Райкомның эше канәгатьләнерлек дип табылды.

Райкомның беренче пленумы 7 кешедән бюро сайлады. Райкомның беренче секретаре итеп Семенов, икенче секретаре итеп Камалов, кадрлар буенча секретарь итеп Поплавский иптәшләр сайланды.

☘

Бондюг районының партконференциясе 3 көн дәвам итте. Райком секретаре иптәш Баһаветтиновның отчет-доклады буенча 46 кеше чыгыш ясады.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Райком пленумының яңа составына 31 член һәм 7 кандидат сайланды. Пленум райкомның беренче секретаре итеп иптәш Баһаветтиновны, икенче секретарь итеп иптәш Ижболдинны, кадрлар буенча секретарь итеп иптәш Абдуллинны сайлады.

☘

Биектау районы коммунистларының отчет сайлау җыелышы үткәрелде.

Иптәш Кузнецов райкомның эше турында отчет ясады. Фикер алышуларда 24 кеше чыгып сөйләде. Чыгыш ясаучылар ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүче коммунистларга начар булышлык итүе өчен пропаганда һәм агитация бүлеге работникларын нык тәнкыйтьләделәр.

Конференция райком пленумы составына 21 член һәм 5 кандидат сайлады. Пленумның беренче утырышында Кузнецов, Ибраһимов һәм Зубков иптәшләр ВКП(б) райкомы секретарьлары итеп сайландылар.

Әлки районы урта мәктәбе янындагы ВЛКСМ комитеты үзенең чираттагы утырышында оборона ярышы мәсьәләсен тикшерә.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ТАССР-ның XX еллыгына хәзерлек

КҮП СТАНОКЧЫЛАР САНЫ АРТА

С. М. Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводының иптәш Усманов җитәкчелек итә торган цех коллективы республикабызның XX еллыгын лаеклы каршылау өчен яңа йөкләмәләр алган иде. Хәзер бу йөкләмәләр намус белән үтәлә.

Бу цехта күп станокта эшләүчеләр саны көн саен арта. Элек җыештыручы булып эшләгән иптәш Хәсәнова Зәйтүнә хәзер бер юлы икешәр станокта эшли һәм производство заданиесен 200 процент итеп үти. Стахановчылардан Волоснов, Телешев һәм башка иптәшләр икешәр һәм өчәр станокта эшләп көнлек нормаларын 116—150 процент итеп үтиләр. Сафиуллин, Нәҗмиев, Уваров иптәшләр ике станокта эшләп көнлек заданиеләрен 120—130 процент итеп үти башладылар.

Х. Гарифуллин.

ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ ТУЛЫ ҮТӘРГӘ

Серго заводы коллективы 1940 нчы ел планын 24 нче декабрьгә, ә ярты еллык планны Татарстанның XX еллыгына үтәү өчен көрәшә.

Хәзер заводта алдынгы цехлар, сменалар, участкылар һәм аерым стахановчылар алган йөкләмәләрне практик эш белән ныгыталар. Иптәш Кузьмин җитәкчелек итә торган цехның аерым участкылары айлык план үтәлешен 120—130 проценттан киметмиләр. Иптәш Оборин җитәкчелек итә торган цех коллективы айлык планын 120 процент итеп үти. Күп станокларда эшләүчеләрдән Маслов, Юсупов, Максимова, Лежнин, Гыйлманов һ. б. иптәшләр заданиене һәр вакыт 250—400 процент үтиләр. Хәзер заводта норманы һәр вакыт арттырып үтәүче күп станокчылар һәм берничә профессияне үзләштерүчеләр саны көн саен арта.

Ләкин кайбер цех җитәкчеләре күп станокларда эшләүчеләргә нормаль эш шартлары тудыруга тиешле игътибар биреп җиткермиләр. Инструментлар һәм ярым фабрикатлар җитешмәү һәм кайбер станокларның төзек булмавы аркасында эшсез торулар зур гына күләм алган.

Мәсәлән, иптәш Орловцев җитәкчелек итә торган цехта эшләүче комсомолец иптәш Корчагин 3 станокта эшләү теләген белдерде. Ләкин цех җитәкчеләре аның бу теләгенә тиешле игътибар бирмәделәр. Станокларны төзәтү чараларын күрмәделәр, нормаль эшләү өчен кирәкле детальләр белән тәэмин итмәделәр. Шул ук цехта эшләүче Варламова һәм Сазыкина иптәшләр белән дә шундый ук хәл. Иптәш Сазыкина 2 станокта эшләп, норманы һәр вакыт арттырып үти, яхшы сыйфатлы продукция җитештерә иде. Хәзер ул тиешле эш шартлары тудырылмау аркасында бер генә станокта эшли. Производствода булган бу тәртипсезлекләр нәтиҗәсендә завод эшчеләренең 20 проценты норманы үти алмыйлар. Җиһазларның эшсез торулары 17 процентка җитә.

Завод җитәкчеләре бу житешсезлекләрне бетерү өчен, барлык цехларның да нормаль эшләүләренә ирешү өчен ашыгыч чаралар күрергә тиешләр.

Б. Камалов.

АЛГАН ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕН НАМУС БЕЛӘН ҮТИЛӘР

Серго Орджоникидзе исемендәге завод коллективы Татарстанның XX еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршы алу өчен зур хәзерлек алып бара. Заводның цех, бүлек һәм участкыларында социалистик ярыш көннән-көн киң колач ала.

Иптәш Исхаков бригадасында эшләүчеләрдән Кудряшов һәм Фазылов иптәшләр көнлек норманы 250—280 процент үтиләр. Тимерчелек цехыннан иптәш Матвеев группасында эшләүчеләр аеруча яхшы эшлиләр. Бу группа февраль аеның 20 көнлек программасын 166 процент итеп үтәде.

Механика цехы мастеры иптәш Бәйрәмева республикабызның XX еллыгына хатын-кызлардан 12 кешене квалификацияле эшкә өйрәтүне йөкләмә итеп алган иде. Хәзер ул бу йөкләмәсен уңышлы үти. Җыю цехыннан иптәш Сесуев җитәкчелек итә торган мастерской коллективы да айлык планны һәр вакыт арттырып үти башлады.

Г. Ялышев.

ХУҖАЛЫК ИСӘБЕНДӘГЕ ПАРОВОЗЛАР

Казан тимер юлында 100 дән артык паровоз хуҗалык исәбенә күчерелде. Аларны папавинчы машинистлардан орденлы Крылов, Захаров, Колыганов, Семин һ. б. иптәшләр йөртәләр.

Машинист иптәш Колыганов (Юдино депосы) норманы бер ярым тапкыр арттырып үти. Иптәш Колыганов обточка арасындагы йөрешне Папавин нормасына—100 мең километрга кадәр җиткерергә карар бирде. Хуҗалык исәбендәге паровозларның машинистларыннан Крылов, Захаров, Шкатов һәм башка күп кенә иптәшләр норма үтәлешен 100 мең километрга җиткерү өчен көрәшәләр.

Хуҗалык исәбенә күчкән машинистларның күпчелеге ремонт һәм майлау материалларына ай саен шактый зур экономия ясыйлар. Орденлы машинист иптәш Крылов (Юдино депосы) узган елның декабрендә 1.808 сум, шушы елның январенда 1.138 сум экономия ясады.

(ТатТАСС).

ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә

БРЕСТ СОЛЫХЫН ТӨЗҮ ӨЧЕН БОЛЬШЕВИКЛАР ПАРТИЯСЕНЕҢ КӨРӘШЕ

1917 нче елның 25 нче октябрендә (7 нче ноябрьдә), Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендәге пролетариат Россиядә эксплоататор сыйныфларның хакимлеген җимерде һәм җир шарының алтыдан бер өлешендә пролетариат диктатурасын—Советлар властен урнаштырды.

Советлар власте үзенең яшь башлавының беренче көннәреннән үк илебезне империалистик сугыштан чыгару өчен көрәш башлады. Советларның II нче съездында солых турында кабул ителгән декрет,—ул Совет властеның тарихи декретларыннан берсе иде. Ленин, Сталин җитәкчелегендәге большевиклар Советлар властенең беренче көннәреннән үк солых өчен көрәш җәелдерделәр. Чөнки Советлар властен саклап калу һәм ныгыту өчен, Кызыл Армияне төзү өчен тын алу (передышка) кирәк иде.

Совет хөкүмәтенең солых турындагы тәкъдимен Англия һәм Франция хөкүмәтләре кабул итмәделәр. Аннан соң Совет хөкүмәте Германия һәм Австрия хөкүмәтләре белән сөйләшүләр алып барырга карар бирде һәм 1917 нче елның 3 нче декабрендә Брест - Литовски шәһәрендә сөйләшүләр башланды. 5 нче декабрьдә Советлар Россиясе белән Германия арасында сугыш хәрәкәтләрен вакытлыча туктату турында булган килешүгә кул куелды.

Солых турындагы сөйләшүләр халык хуҗалыгының һәм сугыш фронтының җимерелүе обстановкасында барды. Сөйләшүләр вакытында Германиянең аннексияле һәм контрибуцияле солых тәкъдим итәчәге һәм иске Россия территориясенең зур кисәкләрен басып алу, Украинаны һәм Балтыйк буендагы крайларны Германия дәүләтенә бәйле илләр итеп калдырырга омтылганлыгы билгеле булды.

Бу вакытта илебезнең саклану көче йомшак иде, иске армия, империалистик сугышта алҗыганлыктан, сугыш өчен көчсез һәм сәләтсез иде. Илебезнең төрле почмакларында буржуазия һәм аның агентурасы—меньшевиклар, эсерлар контрреволюцион мятежлар оештырдылар. Шулай итеп, Советлар иле эчендә гражданнар сугышы көннән-көн җәелә барды.

Антанта (Франция һәм Англия) Германия империализмын туздырып, Советлар иленә интервенция ясарга хәзерләнә иде. Совет хөкүмәте алдында илне эчке контрреволюциядән һәм тышкы интервенциядән саклау өчен Кызыл Армия төзү һәм халык хуҗалыгын яңа баштан кору кебек зур һәм авыр бурычлар тора иде. Шунлыктан илебезнең көчен ныгыту өчен яшь Совет хөкүмәте сепаратный солых ясау юлына барырга тиеш булды.

Партиянең һәм Совет хөкүмәтенең сепаратный солых төзү политикасына троцкичы хиянәтчеләр, меньшевиклар һәм эсерлар бердәм фронт белән каршы чыктылар. Халык дошманнары Троцкий һәм Бухарин җитәкчелегендәге „сул коммунистлар“ группасы сугышны дәвам иттерүне таләп итте һәм партия эчендә Ленингә, Сталинга каршы көрәш алып барды. Бу хиянәтчеләр үзләренең провокаторлык политикалары белән яшь Совет республикасын Германия империализмы удары астына куярга һәм Советлар хөкүмәтен юкка чыгарырга маташтылар.

Бу хиянәтчеләргә җимергеч удар бирел, В. И. Ленин тын алу өчен кирәк булган солыхны кичекмәстән ясауны таләп итте. 1918 нче елның 20 нче январенда Ленин кичекмәстән сепаратный һәм аннексияле солык төзү турындагы мәсьәлә буенча тезис хәзерләде. Лениннең бу тезислары 21 нче январьда Үзәк Комитетның партия активы катнашы белән булган утырышында тикшерелеп кабул ителде. Ленин үзенең тезисларында троцкичы-бухаринчы хиянәтчел политиканы аяусыз рәвештә фаш итте.

В. И. Лениннең директивалары ВКП(б) Үзәк Комитеты утырышында раслануга да карамастан, 1918 нче елның 10 нчы февралендә хиянәтче Троцкийның гаебе буенча солых турындагы сөйләшүләр өзелде. Троцкий, Германия тарафыннан тәкъдим ителгән шартларда солыхка кул куюдан Советлар хөкүмәте баш тарта дип белдерде. Шул ук вакытта ул Германиянең генеральный штабына, яшерен рәвештә, Советлар республикасы көчсез, сугышны алып бара алмаячак һәм армиясен демобилизовать итә, дип белдерде. Троцкийның бу кабахәтлеге нәтиҗәсендә 18 нче февральдә Советлар иленә каршы Германия гаскәрләре һөҗүм итә башладылар. Димәк, Троцкий һәм Бухарин „эштә Германия империалистларына ярдәм иттеләр һәм Германиядә революциянең үсүенә һәм җәелүенә комачауладылар“ (Ленин, том XXII, бит 307).

18 нче февральдә партиянең Үзәк Комитеты утырышында Лениннең һич кичекмәстән солых төзү турында Германия хөкүмәтенә телеграмма җибәрергә кирәк дигән тәкъдиме кабул ителде һәм Германиягә сугыш хәрәкәтләрен туктату турында тәкъдим ясалды. Германия исә Советлар хөкүмәтенең бу тәкъдименә үзенең ризалыгы турындагы җавапны бары тик 22 нче февральдә генә белдерде һәм ул солых шартларын тагын да авыррак итеп куйды.

23 нче февральдә Үзәк Комитет утырышында В. И. Ленин солых ясау шартлары турында доклад ясады. Бу утырышта Лениннең һәм Сталинның хиянәтчеләргә каршы кискен һәм җимергеч удар бирүләре нәтиҗәсендә, немецләр куйган шартларны кабул итәргә һәм солых договорына кул куярга, дигән карар кабул ителде.

Германия белән ике арада солых төзү өчен көрәштә Ленин—Сталин партиясе җиңеп чыкты. 1918 нче елның 3 нче мартында Брест - Литовскида солых договорына кул куелды. Бу договор буенча Советлар республикасы Германиягә 3 миллиард сум контрибуция түләргә, Польшаны, Литваны, Курляндияне, Финляндияне бирергә тиеш булды.

Германиянең союзнигы булган Төркия файдасына Советлар иленең Карас, Ардаган һәм Батуми шәһәрләре бирелергә тиешле иде. Немец гаскәрләренә Украинаны һәм Финляндияне басып алу җиңел булсын өчен Советлар хөкүмәте ул территорияләрдән үзенең гаскәрләрен алырга тиеш иде. Шулай итеп Троцкийның һәм Бухаринның хиянәтләре Советлар иле өчен бик кыйммәткә төште.

„Сул коммунистлар“ (Бухарин, Осинский, Яковлева һ. б.) партиянең Москва өлкә бюросын вакытлыча үз кулларына төшереп, анда Советка каршы карар кабул итүгә кадәр барып җиттеләр. Алар бу карарларында: „Халыкара революция интересларыннан чыгып, без, хәзер саф формаль булып әверелә бара торган Советлар властен югалту мөмкинлеген максатка ярашлы дип саныйбыз“ дип яздылар. („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 247 бит).

Ленин бу карарны „гаҗәп һәм коточкыч“ дип атады һәм „сул коммунистларның“ бу җинаятьләрен бөтен ачыклыгы белән фаш итте. Троцкийның һәм „сул коммунистларның“ партиягә каршы көрәшләренең чын сәбәпләре әле бу вакытта партия өчен ачык түгел иде. Аларның бу кабахәтлекләре 1938 нче елның мартында бухаринчыларга-троцкичыларга булган суд процессында тулысы белән ачылды. 1918 нче елда троцкичылар һәм бухаринчылар берләшеп „...В. И. Ленинне, И. В. Сталинны, Я. М. Свердловны кулга алуны, аларны үтерүне һәм бухаринчылардан, троцкичылардан һәм „сул“ эсерлардан торган яңа хөкүмәт төзүне үзләренә максат итеп куйган булганнар икән“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 247 нче бит).

Солых турындагы мәсьәләне тәмам хәл итү өчен, 1918 нче елның мартында, партиянең VII нче съезды чакырылды. Партиянең VII нче съезды 6 нчы мартта Брест солыхы турындагы мәсьәлә буенча Ленин тарафыннан бирелгән резолюцияне кабул итте.

Ленин, Сталин һәм Свердлов җитәкчелегендә 1918 нче елның 14 нче мартында Бөтенроссия Советларының гадәттән тыш IV нче съезды чакырылды. Съезд 15 нче мартта Брест солыхы договорын раслады.

„Брест солыхын төзү партиягә Совет властен ныгыту өчен, илнең хуҗалыгын тәртипкә китерү өчен вакыт отарга мөмкинлек бирде.

Солых төзү империализм лагерындагы бәрелешләрдән файдаланырга (Австрия—Германиянең Антантага каршы дәвам иткән сугышы), дошманның көчләрен таркатырга, Совет хуҗалыгын оештырырга, Кызыл Армия төзәргә мөмкинлек бирде“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 248 нче бит).

Брест солыхы,—һөҗүм итәр өчен көчләрне туплау максаты белән ясалган вакытлы чигенү,—Лениннең гениаль стратегиясе булды.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе йогынтысы белән Германиядә 1918 нче елның ноябрендә революция башланды. Бу революция нәтиҗәсендә Брест договоры юкка чыгарылды. Шулай итеп, Лениннең: „Солыхның шартлары түзеп булмаслык авыр. Ә шулай да тарих үзенекен итәр... оештыру, оештыру һәм оештыру эшенә. Киләчәк, һичбер нинди авырлыкларга да карамастан,—безнеке“ (Том XXII, бит 288) дигән күрсәтмәсе расланды.

Г. Гыйззәт.

„Трикотаж" артеленең стахановчысы—бригадир иптәш З. Калугина. Ул планны системалы рәвештә 150 процент итеп үти. Л. Попов фотосы. (ТатТАСС фотохроникасы).

РАЙПОТРЕБСОЮЗЛАР ЯРЫШЫ

Этнә һәм Кызыл Юл райпотребсоюзлары үзара ярышып эшләп, 1939 нчы елда план үтәлешендә уңышлы нәтиҗәләргә ирешкәннәр иде. Этнә райпотребсоюзында узган ел товар әйләнеше планы 109,3 процент, Кызыл Юл райпотребсоюзында 112,3 процент итеп үтәлде. Шушы көннәрдә Этнә райпотребсоюзы делегациясе Кызыл Юл райпотребсоюзында ярыш договорының үтәлешен тикшерде һәм күп кенә җитешсезлекләрне ачты.

Иске Тазлар, Кенәр сельполарында һәм аларның бүлекләрендә товарлар тиешенчә сакланмыйлар. Кенәр сельпосының төп кибетендә парфюмерия һәм галантерея товарлары күгәргән тимер кирәкләр һәм селикат товарлары белән бергә саклана. Раймагда брак товарлар сату фактлары бар. Китаплар бүлегендә күптән юкка чыгарылырга тиеш булган китапларны саталар. Ә шул ук вакытта дингә каршы пропаганда һәм агротехника чаралары турындагы иң кирәкле китаплар райсоюз базасында хәрәкәтсез яталар.

Тикшерү вактында, кайбер сельполарның товар әйләнеше планы үтәлешен арттырып күрсәтү фактлары барлыгы беленде. Мәсәлән, Иске Тазлар сельпосы узган елның IV нче квартал отчетында план үтәлешен 31 мең сумга, Кенәр сельпосы 1940 нчы елның январь ае планы үтәлешен 5 мең сумга арттырып күрсәткәннәр.

Ярыш договоры буенча Кызыл Юл райпотребсоюзы узган ел яңадан бер продмаг һәм бер культмаг ачарга тиеш иде. Ләкин договорның бу пункты үтәлмәгән.

Сәүдә стахановчыларының һәм отличникларының дөрес санын райпотребсоюзда да, профсоюзда да белмиләр. Товар әйләнеше планын 86—87 процент кына үтәп баручы Хәмидуллин һәм Ибраһимов, ни өчендер, отличниклар исемлегенә кертелгәннәр.

Кызыл Юл районының сәүдә работниклары язгы чәчүгә яхшы хәзерлек белән каршылау турында конкрет йөкләмә алдылар.

Гыйззәтуллин.

ФИНАНС ПЛАНЫН ҮТӘҮ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ КАЙБЕР ТӘҖРИБӘЛӘР

Татарстанның финанс органнары 1940 нчы елда финанс планын срогыннан алда үтәү өчен Башкыртстан финанс органнары белән ярышалар. Ярыш договоры буенча алынган йөкләмәләрне үтәүдә Чепья районы беренче уңышларга иреште инде. Районда беренче мартка беренче квартал планы 75,1 процент үтәлде.

Финанс планының уңышлы үтәлүенә, район һәм авыл бюджетларына тиешенчә игтибар бирү, бюджетның үтәлешен системалы рәвештә тикшереп тору гаять зур ярдәм итә. Без һәрбер авыл советы буенча бюджетта каралган чараларга, бигрәк тә социал-культура чараларына тиешле сумаларның үз вактында һәм тулысынча бирелүен системалы рәвештә тикшереп торабыз. Бу эштә артта кала башлаган авыл советларында аның сәбәпләрен тикшерәбез. Ә артта калуның сәбәбе күп вакытта бюджетның доходлар өлеше үтәлмәүдән килә. Без бу мәсьәләне шунда ук башлангыч партоешмага һәм актив киңәшмәсенә куябыз, колхозчыларның гомуми җыелышында тикшерәбез. Нәтиҗәдә, финанс туплау эшендә артта калучы авыл советлары алдынгыларны куып җитәләр һәм узып китәләр.

Менә Урбар авыл советы. Ул финанс туплау буенча берничә елдан бирле койрыкта сөйрәлеп килде. Урбар авыл советы хәзер иң алдынгы урынга чыкты. Финанс активистлары, бигрәк тә авыл советының башкарма комитеты председателе иптәш Әскәрев бу эштә зур тырышлык күрсәтәләр. Бу авылда өченче бишьеллык заемы (икенче ел чыгарылыш) узган елга караганда ике тапкыр артыграк урнаштырылды һәм подписчиклар белән расчетлар алдан ук төгәлләнде. Башка түләүләрне җыю эше дә срогыннан элек төгәлләнде. Нәтиҗәдә, Урбар авыл советы 1939 нчы ел бюджетын 140 процент итеп үтәде.

Артта калучы авыл советларына алда баручыларның уңышлы тәҗрибәләрен күчерү бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Бездә үзләренең яхшы эшләүләре белән күпләргә үрнәк булырлык авыл советлары бар. Мондыйлардан берсе итеп Нөнәгәр авыл советын күрсәтергә була. Бу авылда башлангыч партоешма һәм авыл советы колхозчылар арасында массовый-политик эшләрне үрнәк рәвештә оештыралар. Финанс мәсьәләләре турында аңлату эшләре алып баручы активистларга партия оешмасы системалы рәвештә инструктаж үткәрә, аңлату һәм агитация эшенең сыйфатын яхшырту чараларын күрә. Совет бюджетын һәм финанс бурычларын вактында үтәүнең әһәмияте турында стена газеталарында яктыртыла.

Менә мондый яхшы эш үрнәкләрен без җентекләп өйрәнәбез һәм шуның нигезендә барлык активистларны тәрбияләү чараларын күрәбез. Хәзер Чепья районында 500 дән артык финанс активисты бар. Шул исәптән 100 кеше финанс отличниклары һәм ударниклар.

Көшкәт авыл советында иптәш Петров 3.575 сум заем взносын 5 нче ноябрьгә җыеп бетереп, подписчикларга заем облигацияләрен тапшыру эшен дә күптән төгәлләде. Безнең район авыл буенча заем расчетларын республикада беренче булып, 1939 нчы елның декабрь аенда ук тулысынча төгәлләде.

Без үзебезнең эшебездә социалистик ярыш методларын киң кулланабыз. Һәрбер работникның һәм һәрбер финанс активистының индивидуаль рәвештә конкрет йөкләмә алуына ирешү өчен көрәшәбез. Ярыш нәтиҗәләрен һәр декада саен тикшереп торабыз. Бу чара инспекторларны үз участкылары буенча һәр декадага карата конкрет план төзеп эшләргә өйрәтте. Һәрбер работник үз участкысында күпме акча җыелырга тиешлекне декада башында ук яхшы белә һәм декада ахрында үзенең эше турында коллектив алдында хисап бирә.

Хәзер бездә бюджетны үтәмәүче бер генә авыл советы да юк. Безнең район 1939 нчы ел бюджетының доходлар өлешен 112 процент, расходлар өлешен 99,7 процент итеп үтәп чыкты. Финанс планы һәр квартал саен арттырылып үтәлде. Беренче квартал планы 100,3 процент, икенче квартал планы 145,8 процент, өченче квартал планы 141,2 процент, дүртенче квартал планы 112 процент итеп үтәлде.

Мондый уңышларга барлык район финанс бүлекләре дә ирешә ала. Моның өчен эшкә чын-чынлап тотынырга, эшне оештыра белергә, социалистик ярыш методларын киң кулланырга гына кирәк.

ВКП(б) райкомы һәм район советы башкарма комитеты безнең туктаусыз алга баруыбызга зур ярдәм итәләр.

М. Гарифҗанов.

Чепья район финанс бүлеге мөдире.

Казан мехкомбинаты мәктәбенең инструкторы иптәш Е. Л. Камнева эшне яхшы куюы аркасында, аның бригадасындагы барлык эшче хатын-кызлар планны тутырып һәм арттырып үтиләр. Бригада Татарстанның XX еллыгын лаеклы рәвештә каршылау өчен көрәшә. РӘСЕМДӘ: инструктор Е. Л. Камнева (уртада) бригада членнары арасында. А. Усольцев фотосы. (ТатТАСС фотохроникасы).

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 4 март. Кичә информация бюросы болай дип хәбәр итте: „Сугышның ярты еллык йомгаклары Германия гаскәрләренең сугышка сәләтлелеген ачык күрсәтә. Алар дошманны элекке позицияләренә алып ташладылар.

Германия флоты Англия флотын сизелерлек югалтуларга дучар итте. Англия хәрби флотының Скапа Флоудан китәргә һәм Төньяк дингездә операцияләрен киметергә мәҗбүр булуы аның нинди хәлдә икәнлеген бик яхшы характерлый.

Германия авиациясе һавада булган барлык сугышларда өстен булды. Англия истребительләре Германия самолетларының разведка ясауларына һәм Англиянең территориаль суларында конвойлыктагы корабларга һөҗүм итүләренә комачаулый алмадылар".

БЕРЛИН, 4 март. Информация бюросы Англиянең ике истребителе белән Германия самолетлары арасында булган сугыш турында һәм бу сугыш вактында, гүяки, Германиянең бер самолеты бәреп төшерелү, ә ике самолетының качуы турында Гавас агентлыгының 3 нче мартта тапшырылган хәбәрен юкка чыгара.

Информация бюросы, чынлыкта Германиянең 4 самолеты белән Франциянең 12 истребителе арасында сугыш булганлыкны һәм бу сугышта немецләрнең французлар самолетын бәреп төшергәнлекләрен белдерә.

ЛОНДОН, 4 март. Рәсми рәвештә хәбәр итүләренә караганда, 2 нче мартта Ла-Манш проливында Германия бомбардировщигы Англиянең „Донала" пароходын бомбага тоткан. Капитан үтерелгән. Пароходта янгын чыккан. Англия кешеләреннән 48 кешедән 20 кеше һәм һиндлеләрдән 253 кешедән 88 кеше хәбәрсез югалган, аларны үлгәндер дип уйлыйлар. „Донала" пароходы пассажирларының һәм командасының күпчелеген Англия караблары һәм Голландия пароходы коткарганнар. Коткарылучылар арасында яралылар күп. Пароход портка алып кайтылган. (ТАСС).

Финляндиядә Кызыл Армиянең уңышлары турында Болгария матбугаты

СОФИЯ, 4 март. (ТАСС). Болгария матбугаты Кызыл Армиянең хәрәкәтләре турында тулы итеп яза һәм аның һөҗүменең җимерелмәслек көчен күрсәтеп үтә. „Стопански проблеми" журналы болай дип яза:

„12 нче февральдә Ленинград Хәрби Округы Штабының оператив сводкасында Карелия бугазында финнәрнең ныгытылган линияләрен кисkenлек белән өзү турында һәм күп кенә ныгытылган пунктларны алу турында хәбәр ителде. Шуннан соң Совет гаскәрләренең һөҗүме тоткарсыз характер алды. Финнәр икенче ныгытылган полосага алып ташландылар, ә 20 нче февральгә Совет гаскәрләре бугазның бөтен көнбатыш һәм яр буе өлешен алдылар һәм ныгытылган төп пунктка—Выборгка якын ук килделәр".

Аннары журнал, Совет гаскәрләре һөҗүменең бөтен кыенлыкларына да карамастан Маннергейм Финляндиясен тар-мар итү иң якын киләчәктә хәл ителәчәк дип яза.

„Зора" газетасы, Выборгның алынуы уңае белән туган хәлгә тулы анализ ясап, ныгытылган төп пунктның—Выборгның Кызыл Армия кулына күчүе бөтен фронтта яңа стратегик хәл тудырыр дип яза. Газета, Карелия бугазында Совет гаскәрләренең хәрәкәтләре Совет командованиесенең оста тактикасын күрсәтә дип яза.

Карелия бугазында ак финнәрнең җиңелүе турында Элиот

НЬЮ-ЙОРК, 4 март. (ТАСС). „Нью-Йорк геральд трибюн" газетасында Американың атаклы хәрби язучысы майор Элиот Выборгны югалту Маннергеймны „өметсез хәлгә" куя дип яза. Элиот, ихтимал Маннергейм Карелия бугазын ташлап китәргә мәҗбүр булыр, ди.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньягында япон гаскәрләре Наньнин—Биньян шоссесе буйлап Саньтянга таба чигенүләрендә дәвам итәләр. Кытай гаскәрләре Саньтянны чолгап алырга тырышалар.

Гуандун провинциясенең көнчыгыш өлешендә Чаочжоу районында кытай гаскәрләренең атакалары дәвам итә. Японнар ныклы каршылык күрсәтәләр һәм резервлар китерәләр. Сватоудан төньяктарак кытай гаскәрләре японнарны стратегия ягыннан әһәмиятле булган күп кенә пунктлардан бәреп чыгардылар һәм күп кенә санда винтовка, пулемет һәм башка төрле кирәк-яраклар кулга төшерделәр.

Кантоннан төньяктарак японнар 25 нче февральдә шәһәрдән 30 километр ераклыкта кытай позицияләренә атака ясадылар. Сугыштан соң японнар элекке позицияләренә чигенергә мәҗбүр булдылар.

2 нче мартта кытай партизаннары Кантон—Самшуй тимер юлындагы Синань станциясенә атака ясап, японнарның складларын яндырдылар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Кытай гаскәрләре Чжэцзян провинциясендә Сяошань шәһәренә керү юлларын үз кулларында тоталар. Сентрал Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, февральнең икенче яртысында японнарның бу районда 2 меңнән артык кешеләре үтерелгән һәм яраланган.

Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә японнар артиллериясе Лошаньнан чигенүче японнарны эзәрлекләп баручы кытай частьләренә аткан.

Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә Фынсинь районында кытай гаскәрләренең көтелмәгәндә атака ясаулары нәтиҗәсендә японнарның генерал-майоры Сато һәм унбер япон офицеры үтерелгән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә Чжанцзы районында кытай гаскәрләре японнарга ярдәмгә җибәрелә торган гаскәрләргә атака ясыйлар.

„НИЦИ-НИЦИ" ХӘБӘРЧЕСЕНЕН ДАЛАДЬЕ БЕЛӘН БЕСЕДАСЫ

ТОКИО, 4 март. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы „Ници-ници" газетасының Париж хәбәрчесе белән Даладьеның беседасын тулы рәвештә тапшыра. Даладье Франция компаниясенең Юньнань тимер юлын японнарның бомбага тотуыннан борчылганлыгын, ләкин Япония белән Франция арасында үзенең һәр вакыт дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырылачакка ышанганлыгын һәм шуңа ярашлы политика яклы икәнлеген белдергән.

Даладье бу мәсьәләдә Японияне дусларча позициядә торуына һәм ике ил арасындагы төп мәсьәләләрне дусларча тикшерү инде башланганлыкка шатлануын белдергән. Хәбәрче: „Әгәр Франция Япония белән дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырырга тели икән, ул Чан Кай-ши режимын яклау политикасыннан баш тартырга тиеш" дигән. Моңа җавап итеп Даладье Франция хөкүмәтенең Чан Кай-шины якламавын әйткән.

Шуннан соң хәбәрче Юньнань тимер юлыннан Чан Кай-ши режимының файдалануын һәм моның ана Франция тарафыннан ярдәм итү дигән сүз икәнлеген күрсәткән. Даладье Юньнань тимер юлының хәзерге вакытта Кытайның көньяк-көнбатыш өлешен тышкы дөнья белән бәйли торган бер генә буын икәнлеген һәм Юньнань тимер юлыннан Франция файдаланганга караганда АКШ күбрәк файдаланганлыкны, шуның белән бергә Кытай белән Франция арасында сәүдә мөнәсәбәтләренең артык тирән булмавын аңлаткан.

Хәбәрче Англиянең, АКШ ның һәм Франциянең Чан Кай-шига симпатия күрсәтүләрен белдергән. Даладье моны инкар иткән. Хәбәрче, кайберәүләр әгәр Франция, Англия һәм АКШ Чан Кай-шине яклауларын дәвам иттерсәләр Японияне Советлар Союзы белән якынаюы мөмкин дип уйлыйлар дигән. Даладье Японияне Советлар Союзы белән якынаюы яхшы нәтиҗәләргә китермәячәк дип санавын белдергән.

Манчжоу-Гоны Франция хөкүмәтенең тануы мөмкинме дигән сорауга Даладье мондый мәсьәләнең аның хөкүмәте тарафыннан тикшерелмәгәнлеген әйткән, ләкин бу мәсьәләләр буенча якын арада Япония белән Франция арасында сөйләшүләр башланачакка ышаныч белдергән. Хәбәрченең мондый сөйләшүләр кайчан башланачак дигән соравына Даладье мондый мәсьәләләр ике хөкүмәт арасында тикшерелү өчен күтәреләчәкләр дип җавап биргән. Япония хөкүмәте белән Франция хөкүмәте арасындагы сөйләшүләр аларның Токиодагы һәм Париждагы илчеләре арасында алып барылачак.

Франциядән Юньнань тимер юлы аркылы контрабанда товарлары үткәрүне хөкүмәт тыя аламы дигән сорауга Даладье үзенең моңа ачык җавап бирә алмаганлыгын белдергән. Ләкин ул Кытайга сугыш материаллары ташу уңае белән Япония протестларына үзенең каршы килмәвен белдергән. Шулай ук ул Франциянең сугыш кирәк-яраклары чыгаруын да законлы дип санамый. Аннары ул, Япония Юньнань юлы аркылы әйбер ташуны туктатуны тели ала, ләкин юл әле эшләп торганда бу мөмкин түгел, дигән. Мондый такдимнәр Франция өчен кабул ителерлек түгел Ләкин сугышта турыдан-туры файдаланыла торган товарларның Юньнань юлыннан ташылмавы яхшы булыр иде дигән.

КӨЧЛЕ ҺӘМ ҮТКЕН КАЛӘМ

(Ш. Камалның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә 30 ел тулуга карата)

Шәриф Камал Россиядә кара реакция хөкем сөргән көннәрдә әдәбият мәйданына килеп чыкты. Бу көннәрдә интеллигенциянең бер өлеше революциягә хиянәт итте, ренегатлыкка бирелде. „Контрреволюциянең һөҗүме идеология фронтында да барды. Бер төркем модалы язучылар килеп чыкты. Алар марксизмны „тәнкыйть итәләр" һәм „пыр туздыралар" иде, революцияне хурлыйлар, аннан көләләр, хиянәтчелекне мактыйлар". („ВКП(б) тарихының кыскача курсы", 113 нче бит) иде.

Бу чорда татар интеллигенциясе арасында да таркалу башлана. Язучыларның бер төркеме эстетизмга бирелеп, тормышның көндәлек проблемаларыннан кул селки. Ә кайберләре писсимизмга бирелеп, халыктан ераклашырга өндиләр.

Икенче бер төркем революцион демократ язучылар: Габдулла Тукай, М. Гафури, Г. Камаллар буржуа сөремнәренә бирелмиләр, үзләренең каләмнәренә хиянәт итмиләр. Киресенчә, халык кайгысы белән яналар, эксплоататорларга ачы нәфрәт белән тулган әсәрләр язалар.

Шәриф Камал кулына каләм алу белән шушы демократик язучылар рәтенә басты. Капиталистик эксплоатациянең кешелекне җуя торган авыр картиналарын художество чаралары аша гәүдәләндерә башлады. 1905 нче елдан бирле газета-журналларда катнашып килгән Ш. Камал өчен татар буржуазиясенең ике йөзле политикасы ачык иде. Ш. Камал бу сөремнән исермәде, киресенчә, ул үзенең темаларын хезмәт ияләре арасыннан эзләде. Капиталистик тормышта өлешсез булган эшче, крестьян образларын зур симпатия белән гәүдәләндерде, соры кортларны, аларның тәлинкәләрен ялап йөрүче вак җаннарны фаш итте, мәсхәрәләде, штыкка алды.

1901 нче елда язылган „Депутат" хикәясен алыйк. Бу хикәя буржуа парламентаризмыннан оста рәвештә көлә. Либерал буржуа төрле сайлау иллюзияләре белән халыкны тынычландырырга тырыша, Думага сайлануны да халык исеменнән итеп күрсәтергә азаплана. „Депутат" хикәясенең герое да, әнә шул рәвешчә, үзен халык исеменнән сайланган дип күрсәтмәкче була. Петербургка киткәндә үзен озатырга килүчеләр алдында сөйләргә „кайнар" речь хәзерли. Ләкин аны хатынынннан башка озатучы булмый. Вокзалда туктап торган берничә эшче, депутатның сөйли башлаганын күргәч, хатыны белән сөйләшә дип уйлап, кузгалып китәләр.

Шул ук елны язылган икенче хикәя—„Сәмруг кош" хикәясе дә татар милләтчеләренең буржуаз иллюзияләреннән искиткеч ачы көлү белән тулы, аларны мәсхәрәли, пыр туздыра.

Революциягә кадәр үк буржуаз иллюзияләрдән шундый оста көлә белә торган Ш. Камал революциядән соң яңа һәм зур полотноларга күчә, татар буржуазиясенең калдыкларын, аларның февраль һәм октябрь көннәрендә уйнаган контрреволюцион рольләрен 1927 нче елда язылган „Таң атканда" романында бик ачык формада сурәтләп бирә.

Татар буржуазиясе Керенский хөкүмәтен хуплап каршы алды. Ул төрле „Милли шура", „Хәрби шура", „милли полк"лар оештырып, вакытлы хөкүмәткә ярдәмгә килергә тырышты. Буржуазия бөтен көче белән большевикларга каршы, Совет хөкүмәтенә каршы чыкты. Советны танымаска, аны бетерергә юллар эзләде. Мәсәлән, „Таң атканда" романындагы Бикмөхәметовны алып карыйк. Ул исрек, бозык, фахиш кеше. Шулай да ул бөтен шәһәрнең милли буржуаз интеллигентларын үзенең кулында тота. Чөнки аның ярдәменнән башка буржуазиянең ялчы учреждениеләре яши алмыйлар. Шуңа күрә „Милли шура" рәисе Галимов „ике күзе ике якка киткән" Бикмөхәметовка бик инәлеп әллә ничә тапкыр баш ия. „Шәрык" кичәсендә торги барганда, бу акча короле, үзенең иярченнәренә ташлаган берничә йөз сум акча хисабына, буржуа вәкилләре мәҗлесе тарафыннан алкышларга күмелә. Менә аның бу вакыттагы кыяфәте: „Бөтен зал гөр килеп кул чапты. Бу вакытта Бикмөхәметов корт ашаган борчак кузагына ошашлы борнын югары күтәргән, бик тантаналы һәм бөтен дөньяны җиңгән кыяфәттә бер күзе белән көнчыгышка, икенчесе белән көнбатыш якка карап тора иде" („Таң атканда" 104 бит).

„Яңа" бай Сафин вак буржуа интеллигенциясе арасында йөреп, буржуа идеяләрен таратырга җирлек хәзерләүче кеше һәм ул шулай итеп сурәтләнә дә. Сафин „Социализм ул концентрация капитал аркасында гына булырга мөмкин" дигән сүзләр сөйли, үзенең кара фикерләрен социализм буявына бизәкләмәкче була. Сафинның портреты да нак либерал байларча бирелгән. Ул „ак кар шикелле крахмаллы якалар өстеннән ут шикелле кызыл ефәк галстук" бәйләп җибәргән. Октябрь революциясе башлангач Сафин бу „идеяләрне" аерым кешеләргә сөйләү белән бергә трибунага, халык арасына чыга. Үзенең контрреволюцион идеяләрен массага таратырга маташа: „Безгә халык власте, демократия власте, учредительный собрания кирәк". „Бөтен җирдә большевиклар кара халыкны революциягә каршы котырталар" дип большевикларгаяла яга. Кәбиров, Фазлуллин шикелле буржуаз интеллигентлар Сафин фикерен куәтлиләр. Халыкны шул төзелешкә риза булырга, вакытлы хөкүмәткә каршы килмәскә өндиләр. Кәбиров: „Социализм фикерләре белән баш вату, гомумән алганда без татарлар өчен иртәрәк әле дип уйлыйм. Бездә бит байлар сыйнфы башка милләтләрдәгегә караганда бик түбән әле" дигән сүзләр белән капитализмны ачыктан-ачык үстерү лозунгысын күтәреп чыга. Романда алынган башка буржуа вәкилләре дә шушы контрреволюцион карашны уздыралар. Гомумән, „Таң атканда" романы революция елларында татар буржуасының үткәргән реакцион политикасын татар әдәбиятында беренче тапкыр фаш итә.

Татар буржуазиясе һәм буржуаз милләтчеләр Октябрь Социалистик революциясеннән соң советка һәм большевикларга каршы көрәшләрен тагын да кискенләштерделәр. Алар төрле астыртын юллар белән контрреволюциягә материаль һәм мораль яктан ярдәм иттеләр. Солтангалиевчелек һәм башка шундый контрреволюцион оешмалар төзеп, Совет властеның нигезенә балта чабарга, татар совет җәмагатчелеген Совет хөкүмәтенә каршы куярга маташтылар. „Матур туганда" романында гәүдәләнгән Садыйк бай һәм Әмирҗан образлары советка каршы контрреволюция оештыруда рус буржуасы белән кулга-кул тотынып эшләүче кара көчләр булып гәүдәләнәләр.

Әнә шул рәвешчә Ш. Камал татар буржуазиясенең сатлык политикасын 30 ел буенча өзлексез фаш итеп килде, буржуаз милләтчеләрнең кара һәм мәкерле йөзләрен ачты.

Октябрь Социалистик революциясен большевиклар белән бергә көрәшеп каршы алган Ш. Камал революциядән соң зур энтузиазм белән яңа образлар, социалистик төзелеш шартларында җитешкән уңай типлар тудыру юлында эшли башлый. Аның художество чаралары аша яш инженер Габбаслар, карт эшче ударник Сәлимнәр, колхозчы Мәдинәләр һәм күп сандагы шәһәр, авыл активистлары гәүдәләнәләр. Ш. Камал совет патриотларын зур мәхәббәт һәм җылылык белән бирә.

Коммунист Шәриф Камалның үткен каләменнән контрреволюцион буржуаз милләтчеләр һәм һәр төрле дошманнар бер кайчан да качып котыла алмадылар. Моннан соң да аның каләменең сыйнфи үткенлеге кимемәс, киресенчә, һаман да көчәя барыр дип ышанабыз.

М. Фәйзуллина.

8 НЧЕ МАРТ КӨНЕ АЛДЫННАН

ХАТЫН-КЫЗЛАРДАН ФӘННИ РАБОТНИКЛАР

Казан Дәүләт университетында хатын-кызлардан 55 кеше доцент, укытучы, ассистент һәм аспирант булып эшли. Аларның күбесе кандидатлык диссертациясе яклап, докторлык диссертациясе хәзерлиләр. Яш галим хатын-кызлар үзләренең фәнни хезмәтләрендә актуаль фәнни темаларны эшлиләр.

Доцент иптәш Корбангалиева Куйбышев гидроузелы төзелеше уңае белән Татарстанның су бассейннарын өйрәнә. Доцент иптәш Колосова Волга елгасының фитопланктонын тикшерә.

Доцент иптәш Подсосова „Татарстанны физика-география ягыннан районлаштыру" дигән темада кандидатлык диссертациясе яклады. Быелның җәендә ул Волганың уң як яры рельефын өйрәнәчәк. Бу эш тә Куйбышев гидроузелы төзелеше белән нык бәйләп алып барыла.

Доцент иптәш Тихвинская Чебоксар плотинасы районында геологик структураны өйрәнә. Ассистент иптәш Яковлева Чувашстан республикасындагы чүп үләннәрне өйрәнә. Аның күрсәтмәләре нәтиҗәсендә Чувашстан совхозлары чүп үләннәргә каршы көрәш буенча күп кенә уңышлы чаралар үткәрделәр.

Ассистент иптәш Беляева кетгутны бактерияләрдән тазарту буенча кызыклы һәм оборона өлкәсендә зур әһәмияте булган эшне башкарды. Ул бу эше өчен бүләкләнде.

Иптәш Васильева Татарстандагы гөмбәләр турында докторлык диссертациясе яза, Татарстанда ул ашарга яраклы гөмбәләрнең яңа төрен тапты.

Иптәш Замятина үзәк нервы системасын өйрәнү өстендә эшли. Ул үз эшенең бер өлешен академик И. П. Павлов лабораториясендә башкарды.

БӘЙРӘМ КИЧӘЛӘРЕ

Кама Тамагы районының барлык предприятиеләрендә һәм колхозларында Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көнен — 8 нче Мартны лаеклы рәвештә каршылауга эшлекле хәзерлек бара. Предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә кичәләр үткәреләчәк, колхозларда художество үзешчәнлеге кичәләре булачак.

ВКП(б) райкомы колхозларга 29 агитатор җибәрә. Алар анда Халыкара Хатын-Кызлар Көне турында докладлар ясаячаклар.

ТЕГҮ АРТЕЛЬЛӘРЕНДӘ

Татшвейпромсоюз артельләре 8 нче Март Көнен зур уңышлар белән каршылыйлар. Артельләр февраль аеның производство планын 120 процент итеп үтәделәр. „Конфексион" артелендә айлык план 138 процент, „Швейпром" артелендә—136 процент, „Казшвейпром" артелендә—131 процент итеп үтәлде.

Казандагы артельләрдә эшләүчеләр өчен 7 нче мартта сәүдә работниклары клубында тантаналы җыелыш була. Җыелышта 8 нче Март Көне һәм халыкара хәл турында доклад ясала, аннары үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан концерт бирелә. Стахановчылардан 30 кеше бүләкләнәчәк.

Артельләрнең физкультурниклары 8 нче мартта чаңгы ярышы үткәрәләр. Ярышта ирләрдән һәм хатын-кызлардан биш команда катнашачак. Ярышта җиңеп чыгучыларны бүләкләү өчен призлар хәзерләнде.

ЭЛЕМТӘЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР ЯРЫШЫ

Мамадыш районы элемтә бүлегендә 55 хатын-кыз эшли. Алар арасында 15 стахановчы, 17 ударник бар. Элемтәче хатын-кызлар арасында 8 нче Март хөрмәтенә социалистик ярыш җәелдерелде. Шәһәр советы депутаты телефонистка иптәш Гарипова хатын-кызлар арасындагы ярышка җитәкчелек итә. Телефонисткалардан Архангельская, Петрова, Белоглазова, техник Семенова һ. б. иптәшләр һәр көнне норманы 150—180 процент итеп үтиләр.

Район элемтә бүлеге 8 нче Март Көнендә алдынгы хатын-кызларны бүләкләү өчен 1.000 сум акча билгеләде.

АТУ СПОРТЫ ЯРЫШЛАРЫ

Казан шәһәре, Молотов районының Осоавиахим Советы Халыкара Хатын-Кызлар Көне уңае белән, 8 нче мартта хатын-кыз командалары арасында ату спорты ярышлары үткәрә. Ярышларда Осоавиахимның башлангыч оешмаларыннан 5 әр кешелек 25 команда катнаша.

Районның күп кенә учреждение һәм предприятиеләрендә 19 оборона түгәрәге оештырылды. Аларга хатын-кызлардан 108 кеше член булып керде.

ЯЛ ЙОРТЛАРЫНДА ҖӘЙГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Татарстанның ял йортларында җәйге сезонга хәзерлек башланды.

Дачаларга ремонт ясала, кайбер ял йортларында яңа биналар төзелә. ВЦСПС ның ял йортлары һәм санаторийләр идарәсе Татарстанның ял йортларында яңа төзү һәм ремонт эшләренә 800 мең сум, ял йортларын җиһазлауга 500 мең сум акча җибәрде. Узган ел бу эшләргә 1 миллион 100 мең сум тотылган иде.

Моркваштагы балалар санаториендә яңа корпус салынды, электростанция төзелде. Анда быел яңа ашханә, мунча салына, водопровод эшләнә, радиоузел төзелә. Дачаларга, ашханәгә һәм башка урыннарга 30 репродуктор куелачак. Анда шулай ук стационар кино-театр ачыла. Кинотеатрга тавышлы фильмнәр күрсәтә торган аппарат куелачак.

Берсут ял йортында водопровод салына, дачаларга һәм башка биналарга ремонт ясала. Тарловка санаториендә яңа корпус һәм ашханә төзелә.

Ял йортларында җәйге сезон 7—10 нчы майда башланачак. Быел ял йортларына баручыларның саны шактый арта. Узган ел Васильево, Берсут, Петровский һәм Казан ял йортлары аркылы 19.644 кеше, Тарловка санаторие аркылы 2.000 кеше үткәрелгән иде. Быел ял йортларына 22.200 кеше, Тарловка санаториенә 2.180 кеше җибәрелә. Моркваштагы санаторий аркылы 810 бала үткәреләчәк. Көз көне бу санаторийдә олырак яштәге укучылар һәм комсомолецлар дәваланачаклар.

Хезмәт ияләренең ял итүләрен оештыру эшендә җитешсезлекләр дә бар әле. Күп кенә профсоюз оешмалары путевкалардан тулысынча файдалануга җитәрлек әһәмият бирмиләр, хезмәт ияләренә путевкаларны вактында кичектереп бирәләр. Нәтиҗәдә ял йортларына җибәрелүчеләрнең кайберләре 2—3 көнгә кичегеп баралар яки бер дә бармыйча калалар. Мәсәлән, узган ел Татарстанның ял йортларына алынган 693 путевка бөтенләй файдаланмыйча калдырылган.

1940 нчы елда путевкалар алу өчен Татарстанның ял йортлары һәм санаторийләр идарәсе белән договорлар төзергә билгеләнгән срок үтте инде. Шуңа карамастан, Дәүләт учреждениеләре, Тимер юллар, Потребкооперация һәм Он тарту промышленносте работниклары профсоюзларының өлкә комитетлары шушы көнгә кадәр договорлар төземәгәннәр. Барлык профсоюз оешмалары ял йортларына путевкалар алу өчен договорларны кичекмәстән төзәргә һәм хезмәт ияләренең путевкалардан тулысынча файдалануларына ирешергә тиешләр.

Г. Латыйпов.

Зур сарайның эчендә...

Кремль—Казанның иң матур бер почмагы. Ул җәен дә, кышын да матур! Казанга беренче тапкыр килүче кешенең дә, байтак вакыт аерылып торып Казанга әйләнеп кайткан кешенең дә Кремльдә буласы килә.

Ләкин бүген әйтергә теләгән нәрсә Казан Кремленең гүзәллеге, аның стеналары, „Сөембикә" манарасы һәм башка тарихи архитектура корылмалары турында түгел.

Сүз Кремльдә наркоматлар урнашкан зур сарайның эчке культурасызлыгы турында бара.

Сез бу бинаның беренче подъездыннан кергәч, гомергә җыештырылмаган дип уйларлык, зур бер бүлмә аша үтәсез, атналар буена себерелмәгән борма-борма баскычны менгәч, Наркомземга эләгәсез.

Менә озын коридор... Ниләр генә юк бу коридорда: иске баскычлар, өсләре тузан белән капланган өстәлләр, иске шкафлар, аяксыз урындыклар...

Бүлмә ишекләре реклама тактасына әйләнгәннәр. Анда клей табы, кәгаз сәләмәләре, аслы-өсле ябыштырылган игланнар... Коридордагы кием элгечләренең берсендә дә кием юк. Монда кешеләр я кием белән эшлиләр, яки бүлмә эченә салып ташлыйлар.

Мисаль өчен менә бер бүлмә. Монда Кама аръягы производство-территориаль управлениесе урнашкан. Управление яңа, работникларның да байтагысы яңа, ә тәртип искечә. Управление бүлмәсендәге йомшак кушетканың арка терәп утыра торган күн мендәрләре аунап яталар. Кушетка өстендә „дело" лар, портфельләр, кыр сумкалары, бүрекләр, пальтолар... Управление начальнигы иптәш Фролов аяк астында чүп-чар, кәгазьләр өелеп ята. Идән шырпы, тәмәке төпләре белән тулган. Мич агартылмаган, тәрәзә төпләре, рамлары тазартылмаган.

Наркомземның күп бүлмәләрендә әнә шундый күренеш.

Учреждениене, бүлмәне чиста тоту анда эшләүче аерым кешеләрнең үзләренә дә нык кагыла, әлбәттә. Дөрес, эшләүчедән күп нәрсә таләп ителми. Идәнгә төкермәсә, тәмәке төбен кая әләкте анда ташламаса, өс киемнәрен элеп куйса— шул җитә. Ләкин „чисталык сотрудникларга кагыла дип", наркомат сотруднигы занятиедән соң калып мич тә агарта алмый, идән дә юа алмый инде. Аның аерым кешеләре булырга тиеш.

Наркомземга районнардан, колхозлардан кешеләр килгәч, үз учреждениесенең шушындый начар хәлдә булуы белән күп иптәшләрнең йөзләре кызара. Ләкин йөз кызару белән мич агартылмый бит.

Кремльдә, шәһәрнең үзәгендә, халык белән зур элемтә тотарга тиешле наркоматның шушындый культурасызлыгы, ул—кешеләр турында, эш өчен аз гына булса да уңайлы шартлар тудыру турында, үз учреждениеләренең культурасы турында бөтенләй кайгыртмау дигән сүз.

Наркомзем аппараты эшен яңа баштан кору уңае белән яңа идарәләр төзелде. Ләкин югарыда күрсәтелгән культурасызлык күренешләрен яңа баштан кору мәшәкатенең нәтиҗәсе итеп кенә карап булмый һәм мондый хәл бер Наркомземда гына түгел. Шуңлыктан учреждениенең эчке күренешен әдәм рәтенә кертү мәсьәләсе турында ныклап уйларга вакыттыр инде. Наркомземда исә коридор һәм бүлмәләрне чистарту өчен һич булмаса „өмә ясап" берәр чара күрергә тәкъдим итәбез.

Ф. Балыкчы.

Елга транспортының балалар көтепханәсендә (Казан). РӘСЕМДӘ: грузчикларның балалары китаплар сайлыйлар.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Иптәш Молотовның Казанда торуы турындагы материалларны басып чыгару

Соңгы көннәрдә партиянең Казандагы өлкә архивында чиктән тыш җанлылык күренә. Москва, Харьков, Киров һәм башка шәһәрләр газеталарының махсус хәбәрчеләре, Москва музейләренең вәкилләре, җирле матбугат работниклары—хәзер биредә даими кунаклар.

Вячеслав Михайлович Молотовның революцион эшкә керешүен күрсәткән документларны өйрәнү буенча җидди эш алып барыла. Мәкаләләр һәм очерклар языла, документлар фоторәсемгә алыналар.

Татгосиздат „Молотов Казанда" дигән очеркны басып чыгаруга хәзерли. Бу очеркта иптәш Молотовның Казанда революцион эш башлавы, аның биредә партиягә керүе турында, реакция елларында көчле подполье эше, беренче тапкыр кулга алынуы һәм сөргенгә җибәрелүе турында языла. Очерк Татгосиздат тарафыннан чыгарыла торган „Гүзәл кешеләрнең Казандагы тормышы" дигән китапка кертелә. Бу китап Татарстан АССР ның XX еллыгына рус һәм татар телләрендә чыгарылачак.

Узган ел Татгосиздат татар телендә „В. М. Молотов" дигән биографик очерк һәм иптәш Молотовның күп кенә докладларын һәм речьләрен 70 мең данә басып чыгарган иде. (ТатТАСС).

Нефтьнең беренче билгеләре

ЧИСТАЙ, 5 март. (ТатТАСС). Булдырьдагы нефть разведкасының өлкән геологы иптәш Аванесьян түбәндәгеләрне белдерде.

— Кичә, 4 нче мартта, көндез беренче номерлы буровойда 981 метр тирәнлектә бораулаучылар, күмерле катлауга җиттеләр. Нефть горизонты шушы катлауга туры килә. Күмерле катлауның калынлыгы 45—50 метр чамасында булырга тиеш дип уйланыла. 5 нче мартта иртән бу катлау 9 метр тирәнлеккә борауланды. Тыгыз породалар, майлы кара туфрак, ә түбәндәрәк нефть исе ачык бәреп тора торган йомшак ком катлаулары чыга.

Бу катлауны үткәндә скважинадан югарыга менә торган сыек балчыкның өстендә эченә газ тулган нефть күбекләре чыга.

Көньяктан һәм көньяк-көнчыгыштан Татарстан территориясен әйләндереп алган барлык башка нефть районнарында (Самара лукасы, Бугурслан, Туймазы) бу калынлык шундый ук тәртиптә һәм шул ук породалар белән башлана. Башка районнар белән бер төсле булганлыктан, Булдырьда нефть катлавы тагын 10—20 метрдан башланырга тиеш. Нефть катлавының башлануы иртәгә, ягъни 6 нчы мартта көтелә.

Геолог Аванесьян, буровой мастер Хәмидуллин һәм буровой начальнигы Губов иптәшләр Татарстанда беренче нефть чыгуын көтеп буровойда дежур торалар.

СССР ГЕОГРАФИЯСЕН ӨЙРӘНҮ БУЕНЧА ФӘННИ ТҮГӘРӘК

Казан Дәүләт университетындагы география фәнни-тикшеренү түгәрәге СССР географиясен өйрәнүгә зур әһәмият бирә. География факультетының студентлары ел саен Кавказга, Кырымга, Мурманскийга, Советлар Союзының башка өлкәләренә һәм республикаларына экскурсияләр үткәрәләр, фәнни экспедицияләргә катнашалар.

Күптән түгел түгәрәкнең утырышында Баренц диңгезенә бару турында студентка иптәш Старухинаның докладь тыңланды. Ул Яңа Җирдә һәм Шпицбергенда булган.

Якын көннәрдә түгәрәк университетның элекке студенты, хәзер Мурманскийдагы океанография институтының котып бүлегенең фәнни сотруднигы иптәш Киселевның институт эше турындагы докладын тыңлаячак.

Юдино районындагы Глубокое, Лебяжье, Красногорское, Светлое һәм башка күлләрне өйрәнүче түгәрәкчеләр крайны өйрәнү буенча бик күп кыйммәтле материаллар тупладылар.

Татарстанның XX еллыгы уңае белән университетта иң яхшы фәнни-тикшеренү эшенә конкурс оештырылды. Түгәрәкчеләрдән 15 кеше бу конкурска катнашырга теләүләрен белдерделәр.

ИҖАД КҮТӘРЕНКЕЛЕГЕ

Татарстан Сәнгать Эшләре Идарәсенең Минзәләдәге колхоз-совхоз театры, Татарстан республикасының XX еллыгына хәзерлек уңае белән, артистлар арасында иҗад эшләрен тагын да җәелдереп җибәрде.

Театр юбилейгә Тарас Шевченконың „Назар Стадоля", Америка язучысы М. Майоның „Улкаем" һәм В. Масс, Н. Куличенконың „Бакчалар чәчәк ата" дигән пьесаларын хәзерли. Бу пьесалардан тыш театр концерт номерларының санын арттыру һәм сыйфатын күтәрү буенча да эш алып бара.

Артистлар составы юбилейгә хәзерлектә һәм юбилейне үткәрүдә хезмәт күрсәтү өчен өч бригадага бүленде. Бригадаларның берсе инде Мөслим, Сарман һәм Минзәлә районнарына чыгып китте.

Г. Бакмул.

Колхоз базарларын реконструкцияләү

Быел Казанның колхоз базарларында зур төзү эшләре үткәрелә. Узган ел базарларны реконструкцияләүгә 555 мең сум акча тотылган иде. Быел шул ук эшләргә 1 миллион 75 мең сум билгеләнде.

Кайбер базарлар яңа урыннарга күчереләләр. Сталин районының 1 нче номерлы колхоз базарын күчерү өчен Нәриман һәм Ухтомский урамнары чатындагы квартал билгеләнде. Андагы хәзерге базарның бер өлеше яңа участкыга кушылачак. Яңа базарны төзү өчен 600 мең сум капитал салына.

Ягодный һәм Кызыл Армия бистәләрендәге базарлар да яңа урыннарга күчереләләр. Лозовский урамындагы базарда 5.000 квадрат метр мәйданга таш түшәләчәк.

ГӨЛҖАМАЛ ӘБИГӘ 107 ЯШЬ ТУЛДЫ

Апас районы „Яңа ил" колхозы члены Гөлҗамал әби Тимергалиевага быел 107 яшь тулды. Ул үзен яхшы хис итә әле, күзләре яхшы күрә, колаклары яхшы ишетә, тешләре дә нык.

Гөлҗамал әбинең кызлары Хәерниса әбигә хәзер 73, Магсүмә әбигә 71, улы Хәлилгә 52 яшь. Гөлҗамал әбинең балаларының балаларыннан 59 кеше яши.

(ТатТАСС).

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

— Квартирадан урлаучылар. Агрономия урамындагы 13 нче йортта торучы Тукаевның квартирасына караклар йозак ватып кереп, аның 7.600 сумлык киемнәрен урлаганнар. Караклар әйберләрне күтәреп барган вакытта урамда милиционер Вәлиев тарафыннан тотылганнар. Алар З. А. Елистратов һәм Б. А. Золов дигән күптәнге җинаятьчеләр булып чыкканнар. Әйберләр иясенә кайтарып бирелгән.

БЕЛДЕРҮ

7 нче март, кич 6 сәгатьтә ВКП(б) Өлкә Комитетының Партия Мәгарифе йортында, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" ның I нче бүлегенә карата лекция үткәрелә. Тема: „Крепостнойлык хокукының бетерелүе һәм Россиядә промышленность капитализмының үсүе". Лектор — иптәш Устюжанин.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

6 нчы мартган башлап, Чехов, Сукконный, Ягодный колхоз базарларында һәм 1 нче номерлы колхоз базарында
авыл хуҗалыгы продуктлары белән сәүдә итү вакты бер — сәгатькә озайтылды —
Бүгеннән бу базарларда авыл хуҗалыгы продуктлары иртән 7 сәгатьтән кич 5 кә кадәр сатыла.
Казан шәһәре базарлары идарәсе.
442—1

ДӘҮЛӘТНЕҢ
„Кызыл Шәрык" сыра заводы
0,5 һәм 0,6 литрлы
СЫРА ШЕШӘЛӘРЕ АЛА
Шешәләр оешмалардан—Тукай урамындагы 107 нче йортта, ә барлык гражданнардан—заводның Казандагы барлык сыра сату урыннарында алына.
298—3—1

„Главкинопрокат" ның Татарстан бүлеге
шушы көннәрдә Татарстан АССР киноэкраннарына, Киев киностудиясендә эшләнгән

исемле тавышлы, художестволы яңа фильм бирә.
Ф. Кноре сценарие. Режиссерлар: Э. Пенцлин һәм В. Кучвальский.
Баш рольләрдә: орденлы артист М. Бернес, артист В. Дашенко, артистка Е. Голынчик һәм башкалар.
Фильм совет яшьләренең тормыш юллары турында, яшь, кыю командирлар турында һәм алардагы батырлык һәм патриотизм турында сөйли.

Бензин һәм майлау материаллары станциясе конторасы
БАРЛЫК АВТОХУҖАЛЫКЛАР ИГЪТИБАРЫНА
БЕЛДЕРӘ:
Татарстан АССР Совнаркомының 1940 нчы ел, 26 нчы февральдә чыгарган 103 нче номерлы карары нигезендә,
автохуҗалыкларны ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү һәм аның учеты буенча яңа тәртип кертелә.
Шул уңай белән, автохуҗалыклар кулларында булган барлык талоннарны шәһәрдә 10 нчы мартка кадәр, районнарда 15 нче мартка кадәр, ягулык һәм майлау материаллары станциясенә тапшырырга һәм яңа талоннар алу чарасын күрергә тиешләр. Элекке талоннар шушы ел 1 нче марттан гамәлдән чыккан дип исәпләнә.
Талоннар тапшыручы оешмалар, тапшырылган талоннарга счет язарга тиешләр һәм счетта ул тапшырылган талоннарның бензин һәм майлау материаллары станциясе кассасыннан нинди номерлы счет буенча алынган булуы күрсәтелергә тиеш.
396—3—1

КИРӘК:
„ГЛАВПАРФЮМЕР" ның ТАТАРСТАН КОНТОРАСЫНА (Лобачевский урамы, 3) БАШ БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ.
350—3—1

Вахитов исемендәге жиркомбинатка даими эшкә ӨЛКӘН РЕВИЗОР, ИНКАСАТОР, ИНЖЕНЕР-МЕХАНИКЛАР, ТЕХНИК-МЕХАНИКЛАР, ТЕХНИК-ИНСТРУКТОР-МЕХАНИК, ЧЕРТЕЖЧЫЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ИНЖЕНЕР-ЭЛЕКТРИК, ТЕХНИК-ЭЛЕКТРИК, САНТЕХНИКА БУЕНЧА ИНЖЕНЕР, 6—7 нче РАЗРЯД ТОКАРЬЛАР, ФИНАНС БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ һәм ФИНАНС ЭШЛӘРЕН ЯХШЫ БЕЛҮЧЕ РЕВИЗОР. Тукай урамы, 152. Комбинатның кадрлар бүлегенә килергә.
426—2—1

„Жилремонт" артеленә (Володарский урамы, 16) ТӘҖРИБӘЛЕ СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА. Хезмәт хакы килешү буенча.
420—1

Центроэлектромонтаж трестының Казан конторасына, Казанда һәм башка урыннарга китеп эшләү өчен, ирләрдән һәм хатын-кызлардан — БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР, ПРОИЗВОДСТВОЧЫ БУХГАЛТЕР һәм берәр эш буенча квалификация алырга теләгән ГАДИ ЭШЧЕЛӘР. Кирәк кешеләргә тулай торакта урын бирелә. Контораның кадрлар бүлегенә килергә. Казан Банк урамы, 13.
408—5—1

Индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәре тегү мастерскоена даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ИТЕКЧЕЛӘР һәм БАШМАКЧЫЛАР. Университет урамы, 2/51 Телефон 11—48.
359—5—5

ТАТАРСТАН АССР ЛЕСПРОМХОЗЛАРЫНДА АГАЧ МАТЕРИАЛЛАРЫ ТАШУ БУЕНЧА ДАИМИ РӘВЕШТӘ ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ШОФЕРЛАР һәм ТРАКТОРЧЫЛАР. Эш урыннары: ШӘМӘРДӘН (Казан тимер юлы, Шәмәрдән станциясе), ШИРӘМӘТ һәм ТЕЛЬМАН (Кузнечиха районы, Тумба авылы) леспромхозларында. Казанда Наркомлеска (Толстой урамы, 41), ә урыннарда турыдан-туры леспромхозларга мөрәҗәгать итәргә.
374—2—1

Даими эшкә ФИНАНСИСТ, магазиннар һәм предприятиеләр өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, ТОВАР ӘЙЛӘНЕШЕ РАСХОДЛАРЫ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ һәм БҮЛЕК ӨЧЕН БАШ БУХГАЛТЕР. Ягодный бистәсе, Базар мәйданы, Райпищеторг.
370—2—1

Васильево Урман комбинатына даими эшкә, КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК ТЕХНИКАСЫ һәм ХЕЗМӘТ САКЛАУ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. Квартира бирелә. Казан тимер юлының Васильево станциясе, Лесокомбинат конторасы.
361—2—2

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 6 нчы мартта көндез 12 сәгатьтә һәм кич
ШӘМСЕКАМӘР
Талоннар: көндез 128, кич 129.
7 һәм 8 нче мартта
КЫЮ КЫЗЛАР
Талоннар: 130 һәм 131.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык.
ТДАТ.

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
Татар Дәүләт Опера театры постановкалары
Бүген, 6 нчы мартта
Файдасызга саклану
Талоннар: 64 һәм 65.
Кич 8 дә башлана.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 6 нчы мартта, данлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хәйван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган артисты һәм орденлы М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
6 нчы мартта көндез 12 сәгатьтә зур программа буенча
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Кичке уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Подписчиклар игътибарына!
КОГИЗ ның подпискалар — алу конторасы —
Бауман урамына (Матбугат йортына) КОГИЗ ның 1 нче магазинына
КҮЧТЕ
434—2—1

ЯЗУ МАШИНАСЫ САТЫП АЛАБЫЗ
Тәкъдимнәр белән Татнаркомземга 25—88 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.
433—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 6 нчы мартта көндез 12 сәгатьтә
ЛЕНИН
Кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Көндезге спектакльгә талоннар белән кертелми, кич талон 117.
8 һәм 9 нчы мартта
ЛЕНИН
Талоннар: 118 һәм 119.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Зур Драма театры бинасында
7 нче мартта (Талон 83)
ЗУР КОНЦЕРТ
Кич 9 сәгатьтә башлана.
9 нчы мартта
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ИРЕК
Талон 84.
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 5-30, 7, -30 һәм 10 да.	ЯШӘРГӘ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ПАТРИОТ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ДОШМАН ИШЕК ТӨБЕНДӘ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	БЕТХОВЕН КОНЦЕРТЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9 да.	МИНИН һәм ПОЖАРСКИЙ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 739 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 907.